Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№5 (135)

9 апрель 2015 ел



Влад Михневский фотосы

# Унтугызынчы гасыр мохитендә

Ике гасырдан артык тарихы булган КФУ үзенең күркәм традицияләре, гореф-гадәтләре белән дан тота. Күп еллар сакланып килгән традицияләр «династиясе», бүгенге көндә дә үз әһәмиятен югалтмыйча, яңалары белән баетылып тора. Кыска вакыт эчендә танылу алган, студентлар арасында кызыксыну, катнашырга теләк уяткан КФУ студентларының «Язгы бал»ы – шундыйларның берсе. Быел ул 5нче апрель көнне «Корстон-Казань» сәүдә-күңел ачу комплексында узды. Бал елдагыча күтәренке рухта, югары дәрәҗәдә барды һәм катнашучылар үзләрен кабат XIX гасырның дөньяви чарасында дип күзаллады.

## Вакыйгалар эзеннән

**ИКЕНЧЕ АПРЕЛЬ** көнне Татар халкының дәүләт тарихы музеенда «Кладовая времени. Из коллекции археологического музея» дип исемләнгән **КҮРГӘЗМӘ ачылды**. Биредә тәкъдим ителгән иң борынгы экспонатка 200 мең ел. Күргәзмәне оештыруга КФУның ААҖ «Ритэк» һәм «Лукойл»ның хәйрия фонды үткәргән иҗтимагый һәм мәдәни проектлар бәйгесендә грант отуы мөмкинлек бирде. Күргәзмә 30 нчы августка кадәр ачык булачак.

• • • •

КФУда министр урынбасарлары өчен «**ЭФФЕКТИВ ИДАРӘ: СТРАТЕГИЯДӘН АЛЫП, ХӘРӘКӘТКӘ»** дип исемләнгән квалификация күтәрү программасы үз эшен башлады. 6-8нче апрель көннәрендә җитәкче урынбасарлары кануннардагы үзгәрешләр, ришвәтчелеккә каршы көрәш, республиканың иҗтимагый-экономик стратегиясе турындагы яңалыклар белән танышачаклар.

• • • •

Фундаменталь медицина һәм биология институтының аспирантлары, кече фәнни хезмәткәрләре микробиология кафедрасы мөдире Ольга Ильинская җитәкчелегендә **«МИКРОБЛЫ РИБОНУКЛЕОЗНЫҢ ТАБИГЫЙ ДИМЕРЛАРЫ: БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ СЫЙФАТЛАРЫ»** проектын эшлиләр. Әлеге хезмәтнең асылы шешләргә каршы терапияләр өчен яңа дарулар уйлап табудан гыйбарәт. Башкарыла торган проектта бактериаль рибонуклеозларның төзелеше тәгаенләнә. Эзләнү нәтиҗәләре онкоген һәм яман шеш күзәнәкләренең үсешен туктатуга ярдәм итәчәк.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды.*

## Ректорат

# «Юл картасы» үсешкә юл ача

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**

АПРЕЛЬ АЕНДА КФУ ИНСТИТУТЛАРЫ «ЮЛ КАРТАЛАРЫ»Н ЯКЛАУ БУЕНЧА ИМТИХАН ТОТАЛАР. 7 НЧЕ АПРЕЛЬ КӨННЕ УЗДЫРЫЛГАН РЕКТОРАТТА ФУНДАМЕНТАЛЬ МЕДИЦИНА ҺӘМ БИОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫНЫҢ «ЮЛ КАРТАСЫ» ҮЗӘК ТЕМА ИДЕ.


Влад Михневский фотосы

Үсеш планы турында чираттагы чыгыш институт директоры **Андрей Павлович Киясов** тарафыннан тәкъдим ителде. Иң беренче итеп, ул Конкурентлыкка сәләтлелекне үстерү программасының үтәлеш нәтиҗәләренә, галимнәрнең мәкаләләре басылу активлыгы артуга басым ясады. Фундаменталь медицина һәм биология институты эшчәнлеген Хельсинки университеты белән чагыштырып була: бу – һава торышы шартларының охшаш булуына бәйле. Әлеге университетның халыкара фәнни басмалардагы мәкаләләре саны PLOSта (Public Library of Science, Сан-Франциско, Калифорния, АКШ) чыгу хисабына арта икән. Андрей Павлович үз хезмәттәшләренә мөрәҗәгатьтә: «Безгә дә шул җыентыкта басылырга кирәк. Тик анда басылу бәясе – 1350$», – дип өстәде.

Биология буенча инглиз телендә белем бирә торган магистратура программасын булдыру турында фикер яңгырады. КФУ ректоры **Илшат Гафуров**, мондый белгечлек алучыларның киләчәге хакында ныклап уйларга кирәклеген ассызыклады.

«Юл картасы»нда институтның фармацевтика юнәлешен А.М. Бутлеров исемендәге Химия интитутына тапшыру мәсьәләсе дә телгә алынды. Бу өлкәнең күбрәк кайсы фәнгә караву – химиягәме, медицинагамы – киләчәктә тикшереләчәк, дип ышандырды Химия институты директоры **Владимир Галкин**.

КФУ ректоры **Илшат Гафуров,** «юл картасы»на карата шәрехләмә биргәндә, фәнни эшчәнлеккә генә түгел, уку-укыту программаларына да игътибар итү кирәклеген ассызыклады. *«Мондый планнар төзү төп максатларны истә тотып эшләнергә тиеш: пландагы чаралар – бары шул максатларга ирешү юлы. «5:100» проектына нисбәтле эшчәнлек алып барганда гына университетыбыз уку йортларының ТОП-100 халыкара рейтингында югары күтәреләчәк».*

Комиссия фикеренчә, ФМһБ институтының «юл картасы»н эшләп бетерәсе бар әле. Чыгышта башкарылган гамәлләргә хисап һәм дәгъва булып яңгыраган фикерләрнең күп булуын истә тотып, «юл карта»лары турында сөйләшкәндә, аларның КФУ өчен табышлы гына түгел, файдалы булмаган якларын да күрсәтү кирәклеген искәрттеләр.

## Туган тел сагында

# «Хаталардан бергәләшеп көлеп тә куялар...»

**Лилия ГАЛИМОВА**

ӘЛЕ БЕРНИЧӘ ЕЛ ЭЛЕК КЕНӘ ТӨҮЛЕКНЕН ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ВАКЫТЫНДА ЖИР ШАРЫНЫҢ ТӨРЛЕ НОКТАСЫННАН ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНЕП БУЛЫР ДИП, КЕМ УЙЛАГАН? «АНА ТЕЛЕ» ОНЛАЙН-МӘКТӘБЕ БЫЕЛ ФЕВРАЛЬ АЕНДА 6 МЕҢНӘН АРТЫК КЕШЕ УКЫТЫП ЧЫГАРДЫ. ДИМӘК, ТАТАРЧА АРАЛАШУЧЫЛАР САНЫ ТАГЫН ДА АРТТЫ. ӘММА ИГЕЛЕКЛЕ ЭШ МОНЫҢ БЕЛӘН ГЕНӘ ЧИКЛӘНЕП КАЛМАДЫ. УКУЧЫЛАРНЫ ЧЫГАРЫРГА ӨЛГЕРМӘДЕЛӘР, САЙТТА ТАГЫН 4 МЕҢ КЕШЕ ТЕРКӘЛГӘН. БУ ИСӘ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮГӘ МОХТАҖЛЫК ЗУР ДИГӘН СҮЗ.

«Ана теле» проекты кысаларында КФУда онлайн дәресләр үткәрелә. Аларны татар теле һәм гомуми лингвистика кафедраларыннан 20 тәҗрибәле укытучы алып бара. Һәр теркәлүченең он-лайн уку бүлмәсенә керү мөмкинлеге бар. Укучы расписание буенча билгеләнгән вакытта татар теле укытучысы белән 45 минутлык дәрестә катнаша ала. Дәресләр сөйләшүгә, әңгәмә төзүгә генә кайтып калмый. Биредә компьютер графикасы, слайдлар, презентацияләр кулланыла. Мондый дәресләрдә берьюлы алты сайт кулланучысы катнашырга мөмкин. Дәрес тәмамланганнан соң, остаз һәр укучыга җаваплары өчен балл куеп чыга, аннан соң һәрберсенә үз теләк-киңәшләрен язып калдыра.

Әлеге проект 2012 елда старт алды. Ул English First компаниясе платформасында ясалды. Проект кысаларында гына да Тукай телен елына 10 мең кеше өйрәнә ала, уку тәмамланганнан соң, һәр чыгарылышка сертификатлар бирелә. Проектны дәүләт бюджеты финанслый. Шунысы куанычлы: татар телен Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә өйрәнергә теләүчеләр һәм 40лап илдән теркәлүчеләр бар. Татар теленең географиясе киң булуы сөендерә.

*– Бу проектның старты да, хәзерге эшчәнлеге дә бик уңышлы. Беренчедән, ул бик җайлы. Һәр теркәлгән кеше, телне белү дәрәҗәсен билгеләп, үз дәресләрен таба. Белгән әйберне яңадан өйрәнеп тормый. Икенчедән, дәресләр тәмамланганнан соң, сертификат бирелә. Өченчедән, телне теләсә кайда, теләгән вакытыңда өйрәнә аласың. Безнең сайтта хәтта Кытайда яшәүчеләр дә бар. Аларның кайберләре бүгенге көндә университетыбызның әзерлек факультетында белем ала. Дәресләребез коры теорияне өйрәнүгә генә корылмаган. Теорияне җыйнак итеп аңлатып, аралашуга, җанлы сөйләмгә күчәбез. Безнең максат та шул – укучыны татарча сөйләшү дәрәҗәсенә җиткерү. Укытучыларыбыз тәҗрибәле: өйрәтеп кенә калмый, җитешсезлекләрне күрсәтеп, аларны аңлата, кайчак хаталардан бергәләшеп көлеп тә куялар. Өйрәнүчеләр өчен бу психологик яктан да бик җайлы,* – дип фикерләре белән уртаклашты Филология һәм сәнгать Институты доценты, педагогика фәннәре кандидаты Кадрия Фәтхуллова.

«Ана теле» онлайн мәктәбе инде яңа дулкын җыя. Алты меңләп бушаган урынның дүрт меңе инде үз иясен тапкан. Мондый темплар белән барганда, Гаяз Исхакый юраган инкыйраз тормышка ашмас, иншалла!

## Белем баскычлары

# Татар математиклары

**Айгөл АБДРАХМАНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

КФУДА «ИҢ ЯХШЫ АКАДЕМИК ТӨРКЕМ» БӘЙГЕСЕ БАРГАН КӨННӘРДӘ, БЕЗ ДӘ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТӨРКЕМНӘРНЕ БАРЛАРГА БУЛДЫК.



Николай Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтында татар һәм рус телле математика, информатика укытучыларын әзерли торган белгечлек безнең игътибарыбызны җәлеп итте. «Ике телле татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» төркеме кураторы, математика методикасы кафедрасы доценты Шакирова Кадрия Барый кызы үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

**- Кадрия Бариевна, ни өчен Сез нәкъ менә математика юнәлешен сайладыгыз?**

- Моның өчен мин мәктәптә математикадан белем биргән Валентина Михайловна Зулякка рәхмәтлемен. Ул миндә әлеге фәнгә мәхәббәт уятты. Мәктәпне бетергәч, кая барырга дигән сорау бөтенләй тумады. Әти-әни һәм укытучым белән киңәшләштем дә ТДГПУның математика факультетына укырга кердем. Шуннан соң бөтен тормышым шул уку йорты, хәзер инде КФУ белән бәйле. 2014-2015 нче уку елында миңа «Ике телле татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» группасы кураторы булырга тәкъдим иттеләр.

**- Үз төркемегездәге студентлар турында нәрсә әйтә аласыз?**

- Әлеге төркемдә 14 студент укый. Төгәл фәнне якын күрсәләр дә, үзләрен башка өлкәләрдә дә уңай яктан күрсәтәләр. Студентлар арасында җыр, музыка сәнгате, спорт белән җитди шөгыльләнүчеләр шактый. 6 студентыбыз КФУда уза торган «Огонь победы в памяти поколений» шигърият бәйгесендә финалга чыктылар. Төркемдә укучыларның күпчелеге укытучылар нәселеннән булуы ачыкланды. Мәсәлән, Зөһрә Мөхәммәтҗанова киләчәктә дүртенче буын мөгаллим булачак. Шуны әйтергә кирәк: студентлар бер генә мизгелләрен дә бушка уздырмыйлар. Октябрь аенда гына, башка төркем студентлары белән берлектә, «Яшьләр тукталышы» уздырган «XXI гасыр укытучысы» проектында катнаштык.

**- Киләсе уку елында төркемне нәрсә көтә?**

- Практикага игътибар итә башларга вакыт. Татарстан Республикасының атказанган укытучылары белән очрашулар оештырырга уйлыйбыз. Фән белән кызыксынучы егет-кызларыбыз бар, шуңа күрә бу юнәлештә дә эшчәнлек алып барырга кирәк дип саныйм. Гомумән алганда, «Ике телле татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» төркемендә белем алучы студентлар кызыксынучан һәм мөстәкыйль. Алар югалып калмаячаклар һәм, һичшиксез, уңышларга ирешәчәкләр.

**- Сез ничек уйлыйсыз, студентлар өчен куратор кем ул?**

- Әле яңа гына мәктәп бетереп килгән балалар тәҗрибәле кеше ярдәменә һәрдаим мохтаҗ. Кайчакта акыллы киңәш, рухи ярдәм бирүче, терәк булучы кирәк. Куратор - менә шул киңәшче, ярдәм кулы сузучы, терәк.

**- Куратор эшенә алынганда, үз алдыгызга нинди максатлар куйган идегез һәм аларга ирешү өчен нәрсә эшләдегез?**

- Иң төп максат – балаларны югары уку йорты, студент тормышы белән таныштыру һәм имтиханнарга әзерләнүдә булышу. Куратор сәгатьләрендә яңа тормышның үзенчәлекләре турында сөйләштек, кыен ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләдек, 14 кешелек төркемнән бер гаилә ясарга тырыштык. Максат-бурычлар чынга ашты, дип әйтә алам. Беренче сессия нәтиҗәләре дә бик куандырды.

• Бөек җиңүгә - 70 ел!

Бөтен җир шарын тетрәткән Икенче Бөтендөнья сугышының тәмамлануына да 70 ел тула. Еллар үткән саен онытыламы бу зур кайгы? Тирән яралар вакыт үткәч төзәлсәләр дә, аларның эзләре калмыймы? Әлеге канлы тарихның безнең көннәрдә, киләчәктә кабатланмавын теләп, ата-бабаларыбызның данлы җиңүенә тирән хөрмәтемне белдереп, үземнең авылдашым Фарукша бабай турындагы сүземне башлыйм.

# Авылдашым батырлыгы

Алсу СӘЛАХОВА, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

**Кызыклы факт:**
**Бөек Ватан сугышы елларында Әстерханда 28 нче резерв армиясе оештырыла. Бирегә, күләмле хәрби кораллары күчерер йөртү өчен, 350 дөя кече файдаланыган. Машиналар һәм атлар җитмәү сәбәпле, хәрбиләр кыргый дөяләрне тотып, кулга ияләштергәннәр.**

Авылдашларыбыз тасвирлавынча: «Зур зәңгәр күзле, кечкенә буйлы, сабыр, аз сүзле егет», 18 яшен тутыруга, армия сафларына китә. Киров өлкәсе, Жданов районында хезмәт итәргә туры килә аңа. 1941 нче елның 22 нче июнендә сугыш башлангач, хәрби элемтәче һөнәрен үзләштерә. 1942 нче елның 24 нче маенда сугышка кереп, 125 нче артиллерия полкында хезмәт итә башлый. Ниләр генә күрергә туры килми аңа... Башта А.И. Еременко җитәкчелегендә Сталинград фронтында сугыша. Әлеге канкойгыч сугыш, ноябрь урталарыннан башланып, февраль башларында гына тәмамлана. Фарукша абыйның бер истәлегеннән өзек: *«Декабрь урталарында бик көчле салкыннар башланды. Сугыш барганда, бик кирәкле элемтә*



*өзелде, мине, шуны табып, ялгарга җибәрделәр. Табуын таптым, ләкин, кулларым нык туңу сәбәпле, тоташтыра алмыйм. Тырыштым-тырыштым – юк. Шуннан соң, тимерчыбыкның ике ягын туры китереп, авызыма каптым. Элемтә ялганды, ике арада сөйләшү беткәнче шул хәлдә тордым. Бу бик кирәкле сөйләшү иде, шуннан соң безнең солдатлар һөҗүмгә күтәрелделәр һәм җиңү яуладылар».* Кышкы суыкта урамга да чыгасы килми торган кеше буларак, салкын тимерчыбыкны авызда тотып тору өчен күпме көч кирәклеген күз алдыма да китерә алмыйм. Фарукша абый бу батырлыгы өчен «Сталинград оборонасы өчен» медаленә лаек булган.

1943 нче елда Сталинград һәм Курск дугаларында зур җиңүгә ирешкән совет солдатлары алга таба баралар. Фарукша абыйлар да Днепр буен фашистлардан азат итүдә катнаша. Икенче истәлектә мондый сүзләр бар: *«Днепр елгасы янына килеп җиткәндә, яз ае иде. Елга өстендә су, менә-менә боз китәм диеп тора. Елга аша элемтә кирәк. Кечкенә һәм җиңел гәүдәле булганга, мине җибәрделәр. Элемтә йомгагын алып, тәвәккәлләдем. Чыгып кына җитәм дигәндә, тимерчыбык өзелде. Кире киттем, барыбер элемтәне урнаштырдым. Гомерем бетмәгән булгандыр инде, боз өстеннән көчкә чыгып утырдым, өстем юеш, хәл алып утырам, ә дошман якын икән. Шунда иптәшләрем, йөгереп килеп, сөйрәп алып киттеләр, тиз генә тәннәремне спирт белән сөрттеләр».*

Бу батырлыгы өчен Фарукша абыйны «Батырлык өчен» ордены белән бүләклиләр.

Фарукша абыйга күп тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашырга туры килгән, Ходай саклагандыр инде, исән калган. *«Берсендә, яраланып, госпитальгә эләктем. Ике катлы госпиталь яралы солдатлар белән шыгрым тулы. Бервакыт госпитальне немецлар камап алды. Врачлар, санитарлар аякта йөри алган яралыларны урамга чыгардылар, урын өстендә ятучыларга ярдәм итә алмыйлар. Әсирлеккә төшәргә теләмәүчеләргә пистолетлар тараттылар. Немецлар беренче каттагыларның бөтенесен үтереп бетерделәр. Икенче катка менеп җитә алмадылар, урманнан партизаннар килеп коткарып калдылар. Мин икенче катта идем».*

Бик үткен дә булган Фарукша абый. Бер көнне ул разведкага китә. Тиешле урынга җиткәндә, немецлар сизеп алалар, качарга урын булмый. Җирдә үлгән ат ята, Фарукша абый, кечкенә булгач, тиз генә атның эчен ярып, эчәгеләрен алып ташлый да ат эченә кереп ята, шулай исән кала.

Авылдашым 1999 нчы елның 18 нче мартында туган ягында гүр иясе булды. Авыр туфрагы җиңел булсын. Сугышның бар ачысын татыган Фарукша абыйга барлык замандашларым исеменнән рәхмәтемне белдерәм. Ата-бабаларыбызның авыр язмышларын кабатламыйча, тыныч, матур тормышта яшәсәк иде.

• Фән дөньясында

## Андрей Швеев:

## *«Фән өлкәсендә уңыш җиңел генә бирелми»*

Динә ШӘКҮРОВА, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникацияләр институты

Бездә фән өлкәсе элек-электән катлаулы, нинди дер буй җитмәслек биеклек сыман кабул ителә. Бүгенге әңгәмәдәшебез исә үзенең эш-гамәлләре белән моның киресен исбатлый. Сүзем бер ел эчендә «Scopus» базасында 13 фәнни мәкалә (!) бастырган галим, КФУның Яр Чаллы филиалы доценты, «Бердәм Россия» партиясенең Чаллыдагы җирле бүлек әгъзасы Андрей Швеев хакында.

Хәзерге вакытта төрле чыганакларда басылган 60тан артык фәнни хезмәтем бар, – дип башлады ул сүзен. – Шуларның 13е – «Scopus» базасында, 18 мәкалә Югары аттестация комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән журналларда дөнья күрде. Моннан тыш, фәнни хезмәтләр сандыгымда 5 патент һәм 1 монография дә бар.

**– Сез бер ел эчендә 13 фәнни мәкалә бастыргансыз. Мондый нәтиҗәгә ирешүегезнең сере нидә?**

– Фәнни хезмәтләрем, нигездә, инновацион материаллар куллану юлы белән автомобиль техникасы детальләренең хезмәт срогын арттыруга багышлана. Бу исә бүген иң кирәк һәм мөһим юнәлешләрнең берсе. Мәкаләләремә зур игътибар бирелү дә шуңа бәйледер, мөгаен. Бердәмлектә – көч, дигәндәй, нинди дә булса дәрәҗәгә берүзең генә ирешү дә шикле. Шуңа күрә иң элек бердәм команда булып эш итәргә кирәк.



**– «Машина җене» дигәннәре сезгә кайчан кагылды?**

– Автомобильләр белән балачактан кызыксынам. Шәһәрдә үткәрелгән автомобиль ярышларына да еш йөри идем.

**– Автомобильләр ярату белән берррәттән, Чаллы халкы велосипедларны да үз итә бит әле. Ялгышмасам, узган ел сезнең команда шәһәрдә 2030 елга кадәр велотранспорт үсеше стратегиясен тәкъдим итте. Бу проектны тормышка ашыра башладыгызмы инде?**

– Хәзерге вакытта Чаллы буйлап йөрергә мөмкинлек биргән веломаршрут схемалары төзелә, аларга инфраструктура объектлары да кертелә. Стратегия кысаларында «Экотуризм өчен веломаршрут» дигән проект та тормышка ашырыла.

**– Яшьләр димәктән, сер түгел: бүген алар фән өлкәсендә «кайнарга» атлыгып тормыйлар. Мондый шартларда, яшьләрне фәнгә җәлеп итү өчен, нинди ысуллар кулланырга кирәк?**

– Бу фикер белән килешмим. Киресенчә, бүген студент һәм аспирантларның күбесе киләчәктә укытырга, фән белән шөгыльләнергә тели. Әле күптән түгел генә үткәрелгән социологик сораштыру барышында, яшьләрнең өчтән бере шулай дип белдергән. Студентлар арасында икенче курста ук фәнгә тартылучылар бар. Өстәвенә, яшь галимнәргә хөкүмәт тарафыннан да теләктәшлек зур. Бүген аларга ярдәм йөзеннән төрле грантлар бар, чит илдә тәҗрибә туплап кайту мөмкинлеге бирелгән. Яшь галимнәргә үз уйниятләрен тормышка ашыру җиңелрәк булсын өчен, Сколково, IT-парк, Иннополис шәһәрчекләре барлыкка килде. Болар барысы да, фән белән шөгыльләнү һәм төрле инновацион проектларны тормышка ашыру өчен, зур стимул булып тора.

• Эшнең төше

Без, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 4нче курс, 10.2-106нчы төркем студентлары, укытучылыкның нинди җаваплы эш булуына 2 ай дәвамында практика үтү дәверендә кабат инандык.

## *«Алга барганда гына хыяллар якыная...»*

Безнең төркемне белүчеләр дә, белмәүчеләр дә бардыр. Төркемебездә 21 кызга бер егет кеше. Төркемебез бик тә актив студентлардан гыйбарәт. Старостабыз **Эльвина** үзендәге барлык энергияне, көчне безгә дә бирергә тырыша. Гомумән, ул безнең һәр гамәлебезне белеп торучы кеше. Кураторыбыз **Гайнуллина Гөлназ** апа да, 1-2 курсларда кураторыбыз булган **Асылгәрәева Роза** апа да безнең һәр эшебездә киңәш бирүче, яраткан остазларыбыз. Роза апа белән бүгенге көндә дә аралашып, күрешеп торабыз.

Төркемебез Казанның 4 мәктәбендә практика үтте: 27нче һәм 7нче гимназия, 9 нчы һәм 13 нче мәктәпләрдә. Безгә, укучыларыбызда дәресләребезгә карата кызыксыну уяту өчен, аларча фикерләп, алар күзлегеннән эш йөртергә туры килде. Дәресләрдә ныклы белем генә түгел, тәрбия мәсьәләләрен дә чишәргә кирәк. Балалар безне уңай кабул иттеләр, безгә ышандылар, борчулары белән дә, шатлыклары белән дә бүлештеләр, ә без алар өчен «чиксез белем сандыгы», үрнәк булырга тырыштык. Дәрес бирү – дулкынландыргыч бер бәйрәм төсле иде безгә. Укучылар белән уртак тел табарга, туган телебезне өйрәнүгә тагын да зуррак теләк уятырга тырыштык. Үзебез эшләгән эшләрнең нәтиҗәсен күрү – зур бәхет икәнен төшендек, чөнки балалар биргән белемнәрне әйбәт үзләштерделәр. Практика дәвамында бүгенге көн технологияләрен кулланып үткәрелгән дәресләр аеруча кызыклы булды.

Әлбәттә, безнең белән укыту «серләрен» бүлешкәнукытучыларыбызга бик рәхмәтлебез. Методистларыбызның, укытучыларыбызның ярдәмен тоеп эшләү, аларның төпле киңәшләрен ишетү – киләчәктә максатыбызга ирешү өчен алыштыргысыз байлык, дип бәяләр идек.

Укучыларның безне җибәрәсе, ә безнең алар белән аерылышасы килмәде. Укытучы булу - күпләребезнең балачактан бирле күңелләрендә яткан хыялы. Шуны онытмаска кирәк: «Алга барганда гына хыяллар якыная...»



• Безнең канат

# Унтугызынчы гасыр мохитендә



«Язгы бал» – КФУ студентларының уникаль патриотик проекты. 2013нче елда «КФУның ел студенты» проектында җиңү яулаган әлеге чара быел өченче тапкыр оештырылды. Ул илебезнең күптөрле традицияләрен тергезүгә, яшьләрне анын мәдәнияты, мораль-этик, эстетик байлыклары белән таныштыруга юнәлтелгән.

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Бал тантаналы рәвештә град-марш биюе белән башланып китте. Алга таба катнашучылар «Граф Толстой», испан, Паганини вальсларын тәкъдим иттеләр. Чара төрле уеннар, хәйрия ярминкәләре, җырлы-биюле композицияләр, «Театрон» иҗат остаханәсенең сәхнәләштерелгән чыгышлары белән үрелеп барды.

**Ю.Виноградова** проектның идеясен тәкъдим итүчеләр, тормышка ашыручылар, катнашучылар арасында нәкъ менә КФУ студентлары булуын ассызыклады. Шулай ук, әлеге чараның зарурлыгын, традицияләр арасында тоткан мөһим урынын әйтеп үтте.

КФУның «Язгы бал»ы башка баллардан тарихи мохиткә яраклашкан форматы белән аерылып тора. Студентлар дөньяви, борынгы, тарихи-көнкүреш бал биюләрен искә төшерәләр, өйрәнәләр.

Студентларны бал биюләренә өйрәтүче «Fleur de la danse» дөньяви бию мәктәбе җитәкчеләре – Алиса һәм Борис Платовлар сүзләре буенча, әлеге төр бал биюләре, заманча биюләрдән аермалы буларак, җиңүгә һәм призлы урын алуга түгел, ә дөньяви этикет һәм нәзакәтле холык тәрбияләүгә йөз тота.

Студентлар бер ай дәвамында репетицияләргә йөргән, кызлар үзләренә матур бал күлмәкләре, егетләр исә чарага туры килерлек кием әзерләгәннәр. Егетләргә тиешле форматтагы өс киемен табу берникадәр авыррак булган, чөнки балга гадәти костюм киеп килү кискен тыела. Шуңа да карамастан, егетләр үз иптәшләре алдына килешле костюмнардан, аралашу, үз-үзләрен тоту манераларын тиешле дәрәҗәдә үтәүче лаеклы кавалерлар булып килеп бастылар.

Йөзләрендә тыйнак елмаю балкыган, матурдан-матур бал күлмәкләре кигән кызлар да бары соклану хисе генә уятты.

Бал идеясе авторы һәм оештыручы Д.Мөхәммәтҗанова «Язгы бал»ның, студентларны классик биюләргә өйрәтүдән тыш, проект кысаларында аларның тормышка карашын үзгәртүгә, дөньяви, классик биюләр белән даими шөгыльләнүгә этәрә торган чара булуын да искәртеп узды.

Проектны КФУның яшьләр сәясәте, социаль мәсьәләләр һәм физкультура-спорт тәрбиясе системасы үсеше департаменты, Студентлар клубы, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директораты, «Fleur de la danse» дөньяви бию мәктәбе җитәкчеләре һәм «Include» медиа-проекты ярдәме белән КФУның актив студентлары тормышка ашыра.

• Сораштыру

# Прокрастинация чире яисә «студент синдромы»



**Алия КӘЛИМУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Доклад белән реферат әзерлисе бармы, курс эше белән диплом язарга кирәкме? Ә син уку эшләрен «иртәгә, бары тик иртәгә» калдырып, язгы кояш нурларында иркәләнеп йөрисеңме? Димәк, синдә уку йортларында киң таралган «студент синдромы»! Бу авыруның фәнни билгеләмәсе бар икәнен белә идеңме?! Юкмы?! Алайса, тыңла, күр, ишет! Әйе-әйе, фәнни термин белән әйткәндә, без прокрастинация авыруы белән авырыйбыз икән.

Прокрастинация – мөһим эшләрне иртәгәгә калдыру һәм нәтиҗәдә рухи халәткә зыян килү. Сүз ирену, ялкаулык турында бармый. Иренгәндә, без бернәрсә дә эшләмибез, ә прокрастинация булганда, без барлык көнкүреш эшләрен башкарабыз, ләкин иң кирәкле, мөһим булган эшне эшләмәскә тырышабыз – ул «иртәгәгә» кала. Ә безнең студентларыбызда бар микән бу синдром? 5нче курс студентлары диплом эшләрен төгәлләдеме икән?

*Гүзәл Мәхмүтова:*

Дипломны әле яза башламадым, ләкин башларга кирәклеген бик яхшы аңлыйм. Керешеп кенә китә алмыйм: я бер эш, я икенчесе чыгып тора. Ләкин тиздән, үземне кулга алып, яза башлыйм. Биш ел буе фәнни эшләрне соңгы көннәрдә язып өйрәнелгән, бу юлы да шулай булырга охшап тора.

*Альбина Шиһапова:*

Диплом? Ишеткән нәрсәм түгел (*көлә*). Шаярмыйча гына әйтсәк, әлегә диплом эшенә тотынырга вакыт та, сәбәп тә юк. Сәбәбе – яклау көне килеп җиту. Мин үземә максат куям: бүгеннән башлап, фәлән-фәлән көнгә, сәгатькә хәтле шуны эшлим, язам дип үз-үземә ант итәм. Менә шундый принцип белән яшим.

*Лилия Галимова:*

Диплом эшен язуга әле керешмәдем, тик шулай да планы бар. Хәзерге вакытта база, мәгълүмат туплыйм. Язу эшенә соңгы атнада тотына торган гадәтем бар. Әмма диплом – мөһим нәрсә, шунлыктан, аны ким дигәндә, өч атна дәвамында язарга уйлыйм.

*Линар Закиров:*

Дипломның «д» хәрефе дә күренми әле, яза да башламадым. Башка вакытта эшкә кагылышлы биремнәрне «ә» дигәнче эшләп куйсам, соңгы арада мине ялкаулык басты. Дипломны бер атнада язып ташларга ниятлим, шуңа күрә вакытыннан алда пошынмыйм.

*Алисә Сабирова:*

Миңа бөтен кеше «ничек, диплом язып буламы?», «авырмы соң?» дигән сораулар яудыра. Гомумән, бу сезонның иң актуаль соравы бугай ул. Дөресен әйтәм, әле яза башламадым, ләкин бу эшне инде күрә алмыйм. Дипломга һаман керешмәү – бу биш ел уку дәверендә канга сеңеп калган «студент синдромы»дыр инде ул.

Дәүләт имтиханнарына бер атна кала әзерләнә башлаган идем, дипломны да бер ай эчендә язарга өлгерермен әле дигән өметтә калам.

*Фәнзилә Мостафина:*

Минем диплом инде әзер диярек, титул битен дөреслисе һәм әдәбият исемлегенә берничә чыганак өстәп куясы бар. Кышкы каникулларда ук дипломның караламасын әзерләп куйган идем, атна саен аз-азлап яза торгач, бетеп киткәнен сизми дә калдым. Диплом җитәкчем дә, укып, үз бәясен әйтте. Презентация, инфографикалар да ясадым хәтта. Соңгы ноктасын гына куясы калды... Эх-х, болар хыял гына шул. Чынбарлыкта әле диплом турында уйлаган да юк иде. Беркөнне диплом җитәкчем төшкә керде. Усал иде никтер. Хәзер диплом турында уйлана башладым инде. Темасының төп-төгәл ничек яңгыраганын да искә төшерсәләр...

*Динә Шәкүрова:*

Диплом турында соңгы бер-ике көндә генә уйлана башладым, ләкин эшкә керешергә дәрт тә, дәрман да юк... Күп кеше, «диплом язуның нәрсә икәнен дә белмәдем, алдагы курс эшләрен берләштердем дә шуның белән вәссәлам», дип искә ала. Башта шул сүзләр җанымны тынычландырып йөрде, ләкин фәнни җитәкчем, көтмәгәндә, дипломга кагылышлы биремнәр өстәде. Бу: «Динә, эшкә керешергә вакыт»,– дигән билгедер инде. Димәк, җиң сызганып эшкә керешер чак.

• Премьера

# «Кыр казлары артыннан»

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында эшләп килүче «Мизгел» яшьләр театры ел саен тамашачыны премьералары белән шатландырып тора. Театрның режиссеры Марсель Җаббаров спектакльләрне сайлаган чакта классик әдипләребезнең күңелләргә үтеп керердәй драма әсәрләренә тукталуны хуп күрә. Быелгы тукталыш – И.Юзеевның «Кыр казлары артыннан» драмасы.

Басу, елга, авыл йортлары күренешләрен тасвирлаган сәхнә бизәлеше тамашачыны шау-шулы Казан урамыннан тыныч һәм гади генә авыл эченә алып кереп китте.

Артистлар уены шактый югары дәрәҗәдә, барлык хәрәкәтләр, репликалар төгәл, үз урынында. **Илназ Сибгатуллин** тудырган Халик образы, күп илләр гизеп, озак еллардан соң туган җиренә әйләнеп кайткан кешенең үз асылын табуын гәүдәләндерде. Ә инде **Айгөл Миннегалиеваның** (Дәринә ролендә) йөгерек, нәзакәтле, җиңел-җиңел адым-хәрәкәтләре, яңгыравык тавышы – яшьлек чаткыларының үзе. Әлбәттә, бу урында Зөлхия роле турында әйтү кирәк: **Миләүшә Шиһапова** бу образны башкаларга буйсынган һәм сабыр гына соңгы көннәрен көтеп яшәгән карчык итеп сурәтләде. **Ильяс Шаһның** Әкбәренә килгәндә, образның бик драматик һәм, шул ук вакытта, романтик герой булуын ассызыкларга кирәк. **Алсу Габдуллинага** (Ясминә) бик җитди вазифа йөкләнгән иде: спектакльнең кульминацион ноктасының асылы булган «Кыр казлары» җырын башкару. Алсу сынатмады: җыр күңелләрне тетрәндерде, йөрәкләргә үтеп керде.





Вероника Гайнетдинова фотолары

Сәхнә тормышына тәүге кат аяк баскан яшь артист **Ришат Миннемуллин** (Ядкарь) да үз ролен тамашачының хәтерендә бик озак сакланырлык итеп башкарып чыкты.

Тискәре рольләрне уйнавы һәрвакыт авыр: Малик-**Нияз Вәлиуллин** һәм Рим-**Ленар Хамматов** аерым игътибарга лаек. Нияз Маликның фаҗигале язмышын (әтисен кулак дип танулары, сугышта катнашып, дусларын югалтып, үзе исән калу, сугыштан кайткач, барысына да үч саклап, кешеләрне көнләштерергә тырышып яшәве) эчке тетрәнү белән тасвирлады. Тыштан ялтыраган бәхетсез гаилә җимеше булып, улы – Рим үсеп килә. Ул да дөнья малын барыннан да артык күреп, бәхет төшенчәсен үзенчә аңлап, әтисенең яшәү кодексын кабул иткән бер адәм булып формалашкан. Малик һәм Рим образлары, чынлап та, зур осталык белән башкарылды.

Залда яңгыраган «Әрем исе» җыры, артистларның бер-бер артлы сәхнәдән төшеп, зал аша чыгып китүләре Маликның бу дөньяда никадәр ялгыз икәнен ассызыклады. Әрем исе – әрнүле ис. Маликның да йөрәге әрни, әмма инде соңдыр шул.

Әлеге гыйбрәтле драманы тамашачыны сокландырылык итеп сәхнәләштерү – режиссер **М.Җаббарның** һәм «Мизгел» яшьләр театры артистларының зур хезмәте нәтиҗәсе.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.